**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Сәвәләй авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

**№41** **04.08.2021ел**

**"Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Сәвәләй авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында» 2014 елның 24 февралендәге 175 номерлы Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланган Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә, Зәй муниципаль районының Сәвәләй авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Сәвәләй авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. "Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Сәвәләй авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында» 2014 елның 24 февралендәге 175 номерлы Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 14 статьяның 1 өлешендә:

1) 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) Россия Федерациясе гражданлыгы, аның нигезендә чит ил гражданы муниципаль хезмәттә булырга хокук бирә торган Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгы (подданство) туктатылу турында язмача рәвештә муниципаль хезмәткәргә бу хакта билгеле булган көнне, әмма Россия Федерациясе гражданлыгы яисә чит ил гражданлыгы (подданство) туктатылган көннән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә;»;

2) түбәндәге эчтәлекле 9.1 пунктын өстәргә:

«9.1) яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) чит ил гражданлыгы (подданствосы) алу яисә гражданның чит ил дәүләте территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы башка документ алуы турында муниципаль

хезмәткәргә бу хакта билгеле булган көндә, әмма чит дәүләт гражданлыгы (подданствосы) алган яисә чит ил территориясендә гражданның даими яшәү хокукын раслаучы башка документ алган көннән башлап биш көннән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә;»;

1.2. 15 статьяның 1 өлешендә:

а) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) Россия Федерациясе гражданлыгы яисә аның нигезендә чит ил гражданы муниципаль хезмәттә булырга хокук бирә торган Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгы туктатылу;»;

б) 7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса, чит дәүләт гражданлыгы (подданствосы) яисә чит ил территориясендә гражданның даими яшәү хокукын раслый торган паспорты яки башка документы булу;»;

1.3. 24 статьяның 1 өлешендәге 2 пункты үз көчен югалткан дип танырга.

2. Карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Сәвәләй авыл җирлеге**
**Советы рәисе** **С.К.Маклаков**